«РАСЛЫЙМ»

Татарстан Республикасы
мәгариф һәм фән министры
__________ А.Х. Гыйльметдинов
"20" гыйнвар 2012 нче ел

Рус телендә гомуми белем бирүче мәктәпләрнең татар төркемнәрендәге IX сыйныф укучыларына 2012 нче елда ТАТАР ТЕЛЕННӘН яңа формада дәүләт (йомгаклау) аттестациясе уздыру өчен әзерлек дәрәҗәсенә куелган таләпләр һәм эчтәлек элементларының кодификаторы

Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы
тарафыннан әзерләнде

Рус телендә гомуми белем бирүче мәктәпләрнең татар төркемнәрендәге IX сыйныф укучыларына 2012 нче елда татар теленнән яңа формада дәүләт (йомгаклау) аттестациясе уздыру өчен әзерлек дәрәҗәсенә куелган таләпләр һәм эчтәлек элементларының кодификаторы

Татар теленнән әзерлек дәрәҗәсенә куелган таләпләр һәм эчтәлек элементларының кодификаторы (алга таба – кодификатор) 2012 нче елда яңа формада дәүләт (йомгаклау) аттестациясен уздыру өчен контроль бәяләү материаллары эчтәлеген билгеләүче документларның берсе. Ул татар теленнән гомуми белем бирүнең вакытлы стандарты (Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2009 нчы елның 4 нче мартыннан 499 нчы номерлы боерыгы белән расланган) нигезендә төзелгән.

Кодификаторда Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән дәреслекләргә, белем бирү программаларына кертелмәгән әзерлек дәрәҗәсе таләпләре чагылыш тапмый.

Бу документ татар теле буенча төп гомуми белем бирү мәктәп курсы кысаларында имтихан материаллары төзү өчен нигез булып тора, шуңа күрә уку материалын гомумиләштерү һәм системалаштыру принципларыннан гыйбарәт.

Кодификаторда эчтәлеге киңрәк булган блоклар, калын курсив хәрефләр белән язылып, кечерәк блокларга бүленде. Кодификаторның әлеге позицияләренең һәрберсе укыту эчтәлегенең берләштерелгән дидактик берәмлекләрен тәшкил итә. Аларга берничә тематик берәмлек керә ала. Тикшерү биреме төзеләчәк эчтәлек элементының коды икенче баганада күрсәтелә.

1 нче бүлек. Төп гомуми белем мәктәбе курсы буенча татар теленнән имтиханда тикшерелә торган эчтәлек элементлары исемлеге

Төп гомуми белем мәктәбе курсы буенча татар теленнән имтиханда тикшерелә торган эчтәлек элементлары исемлеге[1] татар теленнән гомуми белем бирүнең вакытлы дәүләт стандартына нигезләнеп төзелде.

Бүлек коды	Тикшерелә торган элемент коды	Тикшерелә торган материалның эчтәлеге
1		***Фонетика, орфоэпия, графика, орфография***
	1.1	Татар телендә сузык авазлар

[1] Татар теленнән гомуми белем бирү 5-9 нчы сыйныфлар) баскычында укучыларның белем дәрәҗәсенә таләпләр. Татар теленнән гомуми белем бирүнең вакытлы дәүләт стандарты (Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан 2009 нчы елның 5 нче мартында 499 нчы боерык белән расланган)

	1.2	Тартык авазлар
	1.3	Иҗек калыплары
	1.4	Сүз басымы
	1.5	Ике аваз кушылмасын белдергән хәрефләр
	1.6	ь һәм ъ хәрефләренең дөрес язылышы
	1.7	Икешәр аваз кушылмасын белдергән хәрефләрнең (я, ю, е) дөрес язылышы
	1.8	Сингармонизм законы
	1.9	Ясалма, кушма, парлы һәм тезмә сүзләрнең дөрес язылышы.
2		***Лексика һәм фразеология***
	2.1	Сүзнең лексик мәгънәсе
	2.2	Татар теленең сүзлек составы
	2.3	Антонимнар. Омонимнар. Синонимнар
	2.4	Фразеологик әйтелмәләр
	2.5	Сүзлекләр
3		***Сүз төзелеше, сүз ясалышы***
	3.1	Сүзнең тамыры
	3.2	Сүз ясагыч кушымчалар
	3.3	Сүзне төрләндерүче кушымчалар
	3.4	Татар телендә кушымчаларның тамырга ялгану тәртибе
	3.5	Сүз ясалу ысуллары
	3.6	Сүзнең ясалышын һәм төзелешен тикшерү
4		***Морфология***
	4.1	**Исем.** Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр
	4.2	Исемнәрнең берлек һәм күплек сан формасы
	4.3	Исемнең тартым белән төрләнеше
	4.4	Исемнең килеш белән төрләнеше
	4.5	Тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнеше
	4.6	Исемгә морфологик анализ ясау
	4.7	**Сыйфат.** Асыл һәм нисби сыйфатлар
	4.8	Сыйфат дәрәҗәләре
	4.9	Сыйфатка морфологик анализ ясау

	4.10	**Сан.** Саналмыш
	4.11	Саннарның ясалышы һзм дөрес язылышы.
	4.12	Сан төркемчәләре
	4.13	Санга морфологик анализ ясау
	4.14	**Рәвеш.**
	4.15	Рәвешнең мәгънә төркемчәләре
	4.16	Рәвешкә морфологик анализ ясау
	4.17	**Алмашлык.**
	4.18	Алмашлыкның мәгънә төркемчәләре
	4.19	Алмашлыкка морфологик анализ ясау
	4.20	**Фигыль.** Фигыльнең барлык һәм юклык формасы
	4.21	Фигыль төркемчәләре. Затланышлы фигыльләр
	4.22	Затланышсыз фигыльләр
	4.23	Ярдәмче фигыльләр
	4.24	Фигыльләргә морфологик анализ ясау
	4.25	**Аваз ияртемнәре**
	4.26	**Хәбәрлек сүзләр**
	4.27	**Бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр**
	4.28	**Теркәгечләр**
	4.29	**Кисәкчәләр**
	4.30	**Ымлыклар**
5		***Синтаксис***
	5.1	Сөйләмдә сүзләр бәйләнеше
	5.2	Сүзтезмәләр
	5.3	Җөмләнең баш кисәкләре
	5.4	Иярчен кисәкләр
	5.5	Җөмләнең модаль кисәкләре
	5.6	Аерымланган хәлләр
	5.7	Тиңдәш кисәкләр, алар янында гомумиләштерүче сүзләр
	5.8	Җөмләдә сүз тәртибе
	5.9	Гади җөмлә
	5.10	Кушма җөмлә

	5.11	Тезмә кушма җөмлә
	5.12	Иярченле кушма җөмлә
	5.13	Катлаулы кушма җөмлә
	5.14	Җөмләләргә синтаксик анализ ясау
6		***Пунктуация***
	6.1	Гади җөмләдә тыныш билгеләре
	6.2	Кушма җөмләдә тыныш билгеләре
	6.3	Тиңдәш кисәкләр янында тыныш билгеләре
	6.4	Аерымланган кисәкләр янында тыныш билгеләре
	6.5	Туры сөйләм һәм диалогта тыныш билгеләре
	6.6	Гомумиләштерүче сүзләр янында тыныш билгеләре
7		***Стилистика һәм сөйләм культурасы***
	7.1	Сөйләм культурасы һәм тәрҗемә
	7.2	Татар теленнән рус теленә тәрҗемә итү
	7.3	Рус теленнән татар теленә тәрҗемә итү
	7.4	Стилистик хаталар
	7.5	Татар телендә сүз тәртибе
	7.6	Сүз төркемнәренең сөйләмдә дөрес кулланылышы
8		***Төрле стиль һәм жанрга караган текстларны оештыру***
	8.1	Текст. Текст турында төп төшенчә
	8.2	Темага, максатка, адресатка һәм сөйләм ситуациясенә бәйле тел чараларын сайлау
	8.3	Сөйләмә һәм язма сөйләм стильләре
	8.4	Татар әдәби теленең байлыгы һәм тәэсирле булуы

2 нче бүлек. Төп гомуми белем мәктәбе курсы буенча татар теленнән имтиханда тикшерелә торган әзерлек дәрәҗәсенә куелган таләпләр исемлеге

Югарыда күрсәтелгән стандартта күрсәтелгән төп фикердә укучыларның сөйләм һәм акыл (интеллектуаль) эшчәнлеге истә тотыла.

Бу бүлектә укучыларның татар теленнән төп гомуми белем бирү баскычына куела торган таләпләр күрсәтелә.

Татар теленнән гомуми белем бирүнең вакытлы стандартының төп идеясе – укучыларның сөйләм һәм акыл үсеше. Югары уку йортында белем алу һәм чыгарылыш сыйныф укучыларының киләчәк һөнәри эшчәнлеге өчен кирәкле осталык һәм күнекмәләрне (фәнни текстларны төрлечә уку, үз текстларын төзү күнекмәләре һ.б.) максатчан үстерүгә югары сыйныфларда аерым игътибар бирелә.

Тикшерелә торган күнекмәләрнең исемлеге

1.	Сүзнең аваз-хәреф мөнәсәбәте үзенчәлекләрен белү
2.	Сөйләмне татар әдәби теленең әйтелеш (орфоэпик) нормалары ягыннан бәяли белү
3.	Сөйләмне татар әдәби теленең лексик нормалары ягыннан бәяли белү
4.	Сөйләмне татар әдәби теленең морфологик нормалары ягыннан бәяли белү
5.	Сөйләмне татар әдәби теленең синтаксик нормалары ягыннан бәяли белү
6.	Сөйләмне аңлап, дөрес тәрҗемә итә белү
7.	Грамматик билгеләренә нигезләнеп, сүзнең билгеле бер сүз төркеменә каравын билгели белү
8.	Лексик билгеләренә нигезләнеп, сүзнең билгеле бер сүз төркеменә каравын билгели белү
9.	Сүзгә фонетик анализ ясый белү
10.	Фонетика, лексика, сүз ясалышы, морфология, синтаксис буенча алган белемнәрен телнең орфографик нормаларына яраклаштырып куллана белү
11.	Тыныш билгеләренең куелышын аңлата белү
12.	Сөйләм эшчәнлеге барышында, татар теленең синтаксик нормаларыннан тайпылмау
13.	Язма сөйләмдәге мәгълүматны дөрес, төгәл аңлый белү
14.	Сөйләм стильләрен билгели белү
15.	Сүз ясалышы ысулларын билгели белү
16.	Сүтезмәләргә синтаксик анализ ясый белү
17.	Җөмләгә синтаксик анализ ясый белү
18.	Текстның эчтәлеге турында кыскача төгәл мәгълүмат бирә белү
19.	Башлангыч текстның эчтәлеген аңлый һәм аңлатып бирә белү
20.	Башлангыч текстка нигезләп үз фикереңне эзлекле белдерә белү
21.	Үз фикереңне эзлекле, бәйләнешле белдерә алу
22.	Сөйләмдә телнең лексик байлыгыннан, төрле грамматик конструкцияләрдән урынлы куллана белү
23.	Язма һәм телдән сөйләмне әдәби телнең орфографик, грамматик һәм пунктуацион нормалары нигезендә төзи белү